Another example: in 1968, during an expedition to the village of Ekhmet (Akhmetovo) in the Bua (Buinskiy) District, a manuscript of "Nahj-el-Faradis" by Makhmud Bulgari translated in 1855 (Fig. 5) was discovered, and it helped to supplement certain information related to the literature of this period.



*Fig. 5. Makhmud Bulgari. "Nahj-el-Faradis". v. Akhmetovo, the Buinsky District, 1968.*

In 1969, in the village of Iske Sheimorza (Staroe Shaimurzino) in the Chuprele (Drozhzhanovskiy) District, an archaeological expedition discovered a manuscript of G. Kandalyi's work "Megshukname" ("The Book of Lovers") (Fig. 6). This find was valuable, on the one hand, because it returned this work to the Tatar reader and introduced it into the scientific circulation. On the other hand, it allowed researchers to enrich the literary facts about the writer's work. This is evidenced by the fact that G. Kandalyi's book, published in 1960, contained more than 2,500 poetic texts, while the 1988 edition, compiled by M. Gosmanov, contains 8,500 lines of text [7, p. 154].



*Fig. 6. G. Kandalyi. "Megshukname". v. Staroe Shaimurzino, the Drozhzhanovskiy District. AE- 1969*

In 1984, during an expedition to the village of Mazarbashy in the Berenge (Perenge) District of Mari El, a 1786-page manuscript of the work "Gorbetname" ("The Wanderer's Tale") written by G. Utyz Imani was discovered (Fig. 7). This find is of great importance and is considered today to be the oldest of the manuscripts of this work preserved in the library.



*Fig. 7. G. Utyz Imeni. "Gorbetname", 1786. Mari El, the Perenge District, v. Mazarvashy. AE-1984.*

In addition, among the samples of our literary heritage, one can find the copies of famous and hitherto unknown works of such outstanding Tatar writers as Muhammadyar, Utyz Imeni, Abulmanikh Kargalyi, Hibetulla Salikhov, Gabdelzhabbar Kandalyi, Miftakhetdin Akmulla, and other written sources concerning their translations. It is important to emphasize that many writers' literary heritage, found during these expeditions, was subsequently studied and published in the original and taken by researchers as an object of study, which made a significant contribution to the development of literary criticism.

At the same time, literary monuments of other Turkic peoples were also found during these trips, which allows us to once again emphasize the Tatar people's education, breadth of their views and knowledge of world literature. It is a well-known fact that the Tatars lived in close contact with the Eastern and Central Asian world. In addition, in the Tatar madrasahs, the shakirds used most of the books common in the Eastern world as textbooks. Therefore, in the regions where the Tatars live, copies of works written in Arabic, Persian, Uzbek,

Azerbaijani, Kazakh and Tajik are often found. Thus, in 1968, in the village of Yana (Novoe) in the Astrakhan Region, a copy of the work by the Persian writer F. Gattar "Tezkiretel Euliye" was found (Fig. 8). This find is the oldest of the surviving manuscripts in the Persian language, still kept in the library collection.



*Fig. 8. Gattar. "Tezkiretel Euliye", 1281. The Astrakhan Region, v. Yana. AE-1968*

Among the manuscripts found there are also those written in the Turkmen language. Thus, in 1968 in the Astrakhan Region, a manuscript from the collection of poetry by Mekhtum Kolyi, dating back to the end of the 19th century, was found (Fig. 9). This find is an important source for studying the history of national and cultural ties between the Turkic peoples.



*Fig. 9. A collection of poetry by Mekhtum Kolyi. The end of the 19th century – the beginning of the 20th century. The Astrakhan Region. AE-1968*

A valuable find was the manuscript of the work "Divan" by Galisher Nevai, a famous poet, thinker and statesman of the Uzbek people, who had a great influence on the development of Turkic literature. The manuscript was found in the village of Kaiynlyk (Berezovka) in the Buinsky District (Fig. 10) [23, pp. 73–75].



*Fig. 10. Galisher Nevai. "Divan", the Buinsky District, v. Kaiynlyk. AE-1968*

Thus, the manuscripts and printed books, found as a result of this expedition, remain an indispensable proof on the way to eliminating many "blank spots" that existed in science and clarifying individual facts. These trips allowed many of these monuments to be preserved from disappearance forever, so that they could be passed on to future generations as national cultural heritage.

## 4. Main results

During the expeditions, which lasted for half a century, about 900 settlements in 15 regions of 5 autonomous republics of Russia were studied and more than 10,000 manuscripts, about one and a half thousand printed books written in the Turkic-Tatar, Arabic, Persian languages, covering many areas of science, were collected and transferred to library collections. Most of the found manuscripts are of religious content: Koran, Haftiyak, prayers of various lengths, records of the history of prophets, religious wills, salavats. In addition, a large volume of the collection relates to the field of language, literature, oral folklore, history, medicine and ethics. These expeditions were not limited to collecting manuscript monuments, but were also devoted to studying them; so owing to them, these manuscripts were first introduced into the scientific circulation.

Currently, the Sector of Oriental Manuscripts of the Department of Manuscripts and Rare Books of the Kazan University Library contains more than 15,000 manuscripts. This is the largest figure in Russia. 60 percent of these manuscripts and rare editions are the result of the activities of the archaeographic expedition! They still serve history, language and literary studies, our nation as a whole, and remain an object of study and modern scientific research.

** The photocopies of the ancient manuscript books were taken from the fund of the Manuscripts and Rare Books Department of the Kazan University Scientific Library.*

The research is being conducted within the framework of the FPSP-2/24 theme.

**References**

1. Gosmanov, M. G. (1994). *Po sledam per'evoi ruchki: zapisi arkheografa* [In the Footsteps of a Pen: Notes from an Archaeographer]. 463 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)

2. *Arkheograficheskie ehkspeditsii Natsional'noi biblioteki: 30 letnii opyt* (2022) [Archaeographic Expeditions of the National Library: 30 Years of Experience]. R. Mardano*v*. 250 p. Kazan', “Milli kitaP” (“Natsional'naya kniga) izd. (In Russian)

3. Gosmanov, M. A. (1989). *Skol'ko poter' v kazhdoi nakhodke!* [Aren’t There Many Losses in Every Find!]. Pamyatniki Otechestva. Al'manakh Vserossiiskogo obshchestva okhrany pamyatnikov istorii i kul'tury. No.1, pp. 115–124. (In Russian)

4. Gosmanov, M. A. (1990). *Itogi i perspektivy arkheograficheskikh rabot v Kazanskom universitete* [Results and Prospects of Archaeographic Work at Kazan University]. Materialy itogovoi nauchnoi konferentsii KGU za 1988 god: doklady na plenarnykh zasedaniyakh. Pp. 3–20. Kazan', izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

5. Minnullin, Dzh. S. (2004). *Izvestnyi uchenyi, pisatel', obshchestvennyi deyatel'* [The Famous Scientist, Writer and Public Figure]. Kazan utlary (Ogni Kazani). No. 5, pp. 151–155. (In Russian)

6. Minnullin, Dzh. S. (2015). *Vostochnaya arkheografiya v Kazanskom universitete: stranitsy istorii* [Eastern Archeography at Kazan University: Pages of History]. Tyurko-musul'manskii mir: identichnost', nasledie i perspektivy izucheniya (K 80-letiyu professora M. A. Gosmanov). Pp. 113–118. Kazan', izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

7. Minnullin, Dzh. S. (2023). *Sbornik statei* [Collection of Articles]. 358 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)

8. Krachkovskii, I. Yu. (1960). *Sobranie arabskikh rukopisei v Kazani* [Collection of Arabic Manuscripts in Kazan]. Izbrannye sochineniya. T. 6, 739 p. Moscow-Leningrad. (In Russian)

9. Akhmetzhanov, M. I. (2019). *Izbrannye trudy* [Selected Works]. 336 p. Kazan', IYALI. (In Russian)

10. Gosmanova, D. M. (2014). *Missiya arkheograficheskikh ehkspeditsii v sokhranenii i razvitii traditsii vostokovedeniya i islamovedeniya v Kazanskom gosudarstvennom universitete* [The Mission of Archaeographic Expeditions in Preserving and Developing the Traditions of Oriental Studies and Islamic Studies at Kazan State University]. Islam v mul'tikul'turnom mire: Musul'manskie dvizheniya i mekhanizmy vosproizvodstva ideologii islama v sovremennom informatsionnom prostranstve. Pp. 465–481. Kazan'. (In Russian)

11. Gosmanova, D. M., Mostafina, D. A. (2015*). Traditsii vostochnoi arkheografii v Kazani i Kazanskom universitete* [Traditions of Eastern Archeography in Kazan and Kazan University]. SLAVISTICA VILNENSIS. No. 60, pp. 203–223. (In Russian)

12. Mostafina, D. A. (2015). *Vklad M. A. Gosmanova v osnovanie i deyatel'nost' Arkheograficheskoi laboratorii Kazanskogo universiteta* [Contribution of M. A. Gosmanov to the Foundation and Activities of the Archaeographic Laboratory of Kazan University]. Tyurko-musul'manskii mir: identichnost', nasledie i perspektivy izucheniya (K 80-letiyu professora M. A. Usmanova). Pp. 61–69. Kazan', izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

13. *50-letie Tatarskogo fakul'teta* (1994) [The Tatar Faculty Is 50 Years Old]. 70 p. Kazan', Shəkli fəkhem. (In Russian)

14. *60 let Tatarskomu fakul'tetu* (2004) [The Tatar Faculty Is 60 Years Old]. 143 p. Kazan', Tipografiya Kazanskogo un-ta. (In Russian)

15. *Fakul'tet tatarskoi filologii i istorii* (2004) [Faculty of Tatar Philology and History]. Kazan', B. i. 42 s. (In Russian)

16. *Albert Fetkhi: stat'i i vospominaniya* (2007) [Albert Fetkhi: Articles and Memories]. Sost. Raif Mardanov. 399 p. Kazan'. (In Russian)

17. *Biblioteka vostochnykh istorikov, izdavaemaya I. Berezinym* (1854) [The Library of Eastern Historians, Published by I. Berezin]. T. II, Ch. I, Sobranie letopisei. Tatarskii tekst s russkim predisloviem. XVIII, 128 p. Kazan'. (In Russian)

18. Gotwald, J. F. (1855). *Opisanie arabskikh rukopisei, prinadlezhavshikh biblioteke Imperatorskogo Kazanskogo universiteta* [Description of Arabic Manuscripts Belonging to the Library of the Imperial Kazan University]. 302 p. Kazan'. (In Russian)

19. Karimullin, A. G. (1963). *Vostokovednye fondy biblioteki Kazanskogo universiteta im. V. I. Ul'yanova (Lenina)* [Oriental Studies Collections of the Kazan University Library named after V. I. Ulyanov (Lenin)]. Vostokovednye fondy krupneishikh bibliotek Sovetskogo Soyuza. Stat'i i soobshcheniya. Pp. 228–236. Moscow. (In Russian)

20. Yusupov, A. F., Faizullina, G. Ch. (2024). *Shkola tatarskoi dialektologii v Kazanskom universitete: predposylki, formirovanie i razvitie* [School of Tatar Dialectology at Kazan University: Prerequisites, Formation and Development]. TATARICA. No. 22 (1), pp. 26–48. (In Russian)

21. Garaeva, N. G. (2011). *Stareishii spisok Korana v sobranii Nauchnoi biblioteki im. N.I. Lobachevskogo Kazanskogo (Privolzhskogo) federal'nogo universiteta* [The Oldest Copy of the Koran in the Collection of the Scientific Library Named after N. I. Lobachevsky of the Kazan (Volga Region) Federal University]. Vostochnye rukopisi: sovremennoe sostoyanie i perspektivy izucheniya: Materialy Kruglogo stola (Kazan', 1 dekabrya 2011 g.).

Sostaviteli: R. F. Islamov, S. F. Galimov. Pp. 93–105. Kazan'. (In Russian)

22. Amerkhanova, E. I., Mardanov, R. F., Sabirova, Eh. N. (2023). *Sokrovishcha mysli tatarskikh prosvetitelei* [Treasures of the Tatar Enlighteners' Thoughts]. "Vernost' istine": K 200-letiyu istorika, lingvista i pedagoga Khusaina Faizkhanova: buklet vystavki v Muzee istorii KFU (18 maya – 3 iyunya 2023 goda). Pp. 12–19. St. Petersburg. (In Russian)

23. *Rukopisi Alisher Nevai v sobraniyakh kazani. Katalog* (2021) [Manuscripts of Alisher Nevai in the Collections of Kazan. A Catalog]. Sostavitel' i avtor opisaniya rukopisei – d. i. n. I. V. Zaitsev. 192 p. Moscow– Kazan' – Tambov. (In Russian)

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА АРХЕОГРАФИК ЭКСПЕДИЦИЯ

**Айрат Фаик улы Юсупов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru

**Энҗе Наил кызы Сабирова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Endzhe.Sabirova@kpfu.ru

**Нурфия Марс кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru

Казан университетында оешкан археографик экспедиция, Россиянең 5 автономияле республикасы һәм 15 өлкәсендәге 900 гә якын торак пунктта булып, төрки-татар, гарәп, фарсы телләрендә язылган 10 000 нән артык кулъязма, мең ярымга якын басма китапларны татар укучысына кайтара, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. Табылган кулъязмалар арасында дини эчтәлектәге Коръән Кәрим, Һәфтияк, догалыклар, пәйгамбәрләр тарихына багышланган дини язмалар, тел, әдәбият, халык авыз иҗаты, тарих, медицина, әхлак өлкәсенә бәйле ядкярләр күпчелекне тәшкил итә. Бу экспедицияләрнең әһәмияте кулъязма ядкярләребезне җыю, туплау, гыйльми яктан тикшерү белән генә чикләнеп калмыйча, үз вакытында аларны мәңгегә югалудан саклап калу ягыннан да бәһасез була.

Мәкалә чикләрендәге эзләнүләрнең төп максаты – Казан университетында эшләп килгән археографик экспедициянең тарихын әдәби аспектта өйрәнү, гыйльми һәм милли-мәдәни әһәмиятен билгеләү.

Тикшеренү барышында әлеге экспедициянең әдәбият белеме үсешенә керткән өлеше, гомумән, татар халкы яшәешендәге роле тәгаенләштерелә, ярты гасыр дәвамында оештырылган әлеге сәфәрләрдә табылган кулъязмаларга һәм сирәк басма китапларга күзәтү аша аның фәнни һәм иҗтимагый әһәмияте ассызыклана. Мәкаләнең яңалыгы һәм актуальлеге шуның белән билгеләнә.

**Төп төшенчәләр:** Казан университеты, археографик экспедиция, кулъязма, басма китап, фәнни эшчәнлек

## Кереш

Фундаменталь фәнни куәскә ия гыйльми үзәкләрнең берсе буларак, ориенталистик эзләнүләрне даими күз уңында тоткан Казан университеты тарихында Татарстан һәм Россиянең төрле төбәкләрендәге төрки-татар, гарәп, фарсы телләрендәге кулъязмаларны, иске басма китапларны җыю һәм туплау максатыннан оештырылган археографик экспедиция аерым кыйммәткә ия. Ярты гасыр дәвамында оештырылып килгән әлеге экспедиция уку йортындагы озын гомерле, бай тарихлы экспедицияләрнең берсе буларак та әһәмиятле.

Узган гасырның алтмышынчы елларыннан даими эшләп килгән археографик экспедиция гаять әһәмиятле, әле хәзер дә актуальлеген югалтмаган берничә максатны күздә тотып

оештырыла. Бер яктан, татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә таралып яткан язма ядкярләрне, каурый каләм белән язылган борынгы кульязмаларны, басма китапларны, документларны җыю-туплау, шул рәвешле бай милли-мәдәни мирасны саклап калу күздә тотыла. Икенче яктан, аларны гыйльми аспектта өйрәнү, әһәмиятлеләрен кабаттан бастырып чыгару һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрү бурычы алга куела. Өченчедән, «хосусый архивлардагы документларны, шәхси китапханәләрдәге кульязма истәлекләрне барлау да, рәсми булмаган урыннарда сакланышлары тәэмин ителмичә яткан тарихи материалларны бер урынга – рәсми урынга туплау да экспедиция бурычына керә» [1, б. 19].

Казан университетында тәүге адымнары XIX гасырда ук ясала башлаган археографик эзләнүләрнең рәсми башлангычы 1963 елга тоташа. 1963 елдан 1988 елга кадәр ул уку йортының СССР тарихы кафедрасы, 1989 елдан алып яңа оештырылган татар халкы тарихы кафедрасы каршында эшләп килә. 1963 елдан алып 1989 елга кадәр экспедиция Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә дәвамлы һәм эзлекле төстә эшләп килсә, 1990 елдан бу эшкә Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин алына. 1992 елның җәеннән 2012 елга кадәр әлеге экспедиция Милли китапханәнең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге белән берләштереп оештырыла [2, б. 14].

Казан университетында кульязмалар туплау процессы, археографик экспедициянең аерым чорлардагы эшчәнлеге М.Г. Госманов [1; 3; 4], Җ.С. Миңнуллин [5; 6; 7], И.Ю. Крачковский [8], М.И. Әхмәтҗанов [9], Р.Ф. Мәрданов [2], Д.М. Госманова [10; 11], Д.А. Мостафина [11; 12] һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә өйрәнү объекты итеп күтәрелә. Татар факультетының төрле еллардагы юбилейларына атап эшләнгән китапларда да археологик экспедицияләр хакында аерым фикерләр урын ала [13; 14; 15].

## Хезмәтнең методологик нигезе

Әлеге мәкаләдә Казан университетындагы археологик экспедициянең тарихына экскурс ясау, аның фәнни һәм милли-мәдәни, әдәби яктан ролен билгеләү, бу өлкәдә хезмәт куйган галимнәрнең тырышлыгы белән табылган борынгы кульязма һәм басма китапларның иң әһәмиятлеләренә күзәтү ясау бурычы куела.

Мәкаләне язу барышында, төп методлар буларак, тасвирлама, эзләнү һәм аксиологик методлар үзәккә куелды. Тасвирлама метод археологик экспедиция нәтиҗәсендә табылган мирасны өйрәнү юлында файдаланылды. Эзләнү һәм аксиологик методлар уку йорты белән бәйле археологик экспедиция тарихын өйрәнү барышында кулланылды.

## Фикер алышу

Рәсми төстә 1963 елдан юл ала дип саналса да, Казан университетында археографик эзләнүләр бай тарихка ия. Университетта көнчыгышны өйрәнү мәктәбенең башында торучы профессор Х.Д. Френ (1782–1851) вакытлы матбугатта гарәп телендә язылган тарихи һәм әдәби эчтәлекле кульязмалар сатып алуы турында игълан бирә (1811 елда «Казанские известия» газетасының 11 нче саны) һәм иң беренчеләрдән булып, шәркый кульязмаларны җыю һәм өйрәнүгә кызыксыну уята. Х.Д. Френның хезмәттәше И. Хәлфин (1778–1892), укыту эшендә кулланма буларак файдалану ниятеннән, аеруча тарихи кульязмаларны туплау һәм аларны фәнни әйләнешкә кертүгә зур өлеш кертә [16, б. 118-119]. Мисал өчен, 1819 елда нәшер ителгән «Әхвале Чыңгызхан вә Аксак Тимер» басмасының тексты И. Хәлфин тарафыннан табыла һәм эшкәртелә. 1602 елда Касыйм шәһәрендә язылган һәм безнең көннәргә кадәр сакланып калган әсәрләрнең берсен – Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъ-ет-тәварих» әсәрен дә – университет китапханәсенә Хәлфин тапшыра. Соңрак бу хезмәт И.Н. Березин (1818–1896) тарафыннан бастырыла [17].

Шәркый кульязмаларны җыю һәм бастыру эше Карл Фукс (1776–1846), Мирза Казем-бек (1802–1870), Илья Березиннар (1818–1896) [1, б. 21] тарафыннан дәвам иттерелә. XIX йөзнең урталарына университетның көнчыгыш кульязмалар фонды Европа күләмендә иң бай эчтәлекле һәм күләмле коллекцияләрнең берсенә әверелә [18, б. 7]. Кызганычка каршы, 1855 елда университетның Шәрекъ бүлеге Петербург университетына күчерелү сәбәпле, китапханәнең көнчыгыш кульязмалар фонды тулысынча башкалага җибәрелә. Билгесез сәбәпләргә нисбәтле рәвештә, бәлки алар укучыга кулга бирелгән булгандыр, әлеге коллекциядән барлыгы 3 кульязма гына китапханәдә кала [16, б. 121].

1878 елда Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең ачылуы борынгы кульязмаларны һәм сирәк китапларны туплау эшен киңәйтү

мөмкинлеген бирә. Бу чорда Казан университетында кульязмалар җыю эше белән китапханә мөдире Иосиф Готвальд (1813–1907) актив шөгыльләнә һәм кульязмалар фондын баетуга үз өлешен кертә. 1895 елда ул китапханәгә 95 шәркый кульязманы үз эченә алган шәхси коллекциясен бүләк итә. Хәзерге көндә бу тупланма аерым фонд буларак саклана. 1900 елда профессор Н.Ф. Катанов (1862–1922) Готвальд фондындагы кульязмаларның тасвирламасын бастыра. Үз чиратында, кульязмаларны җыю, тикшерү эшен дәвам итеп, Н.Ф. Катанов Идел буе, Урта Азия, Байкал арты, Монголия һәм төньяк-көнбатыш Кытайга оештырылган экспедицияләрдә катнаша, кыйммәтле кульязмалар һәм китаплар коллекциясе туплый [19, б. 232]. Кызганычка каршы, аның 3600 томнан гыйбарәт китапханәсе белән бергә табылган кульязма берәмлекләр дә Төркиягә китә [1, б. 22].

XX йөзнең егерменче елларыннан кульязмаларны һәм сирәк китапларны туплау эше 1919–1921 елларда Казан университеты рабфагында укыткан, Казан университеты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте белән актив хезмәттәшлек иткән Сәид Вахиди (1887–1938) исеме белән тыгыз бәйләнештә үсеп китә. Аның тырышлыгы белән халык кулында сакланып яткан 3000 нән артык китап һәм кульязмалар табылып, китапханәләргә, фәнни институт фондларына тапшырыла. Мисал өчен, егерменче елларның урталарына аның тарафыннан 200 дән артык кульязма тупланып, ТАССР Дәүләт музеена, 1930 елда 1127 кульязма китап Татарстан гыйльми-тикшеренү экономик институтына, 1934 елда 500 дән артык кульязма СССР Фәннәр Академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтына тапшырыла. Болар арасында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», М. Болгариның «Нәһҗ әл-фәрадис», «Тәварихы Болгария», «Дәфтәри Чыңгызнамә» [1, б. 30-31] һ.б. әсәрләр дә була. М. Госманов билгеләп үткәнчә, «кульязма җыяр өчен халык арасына чыгу идеясе дә, Сәид Вахиди эшчәнлегендә матди гәүдәләнеш табып, реаль идея, алыштыргысыз чара – юл сыйфатында мирас» [1, б. 33] булып кала. Шуңа да Казан дәүләт университетында эшләп килгән археографик экспедиция Сәид Вахиди эшчәнлеген дәвам итә, үстереп алып китә дип санала һәм «Казан ориенталистика мәктәбенең Көнчыгыш кульязма мирасны җыю һәм өйрәнү өлкәсендәге традицияләрен торгызу» [7, б. 153] буларак бәяләнә.

Утызынчы еллардагы вазгыять һәм Бөек Ватан сугышы белән бәйле төстә бераз тукталып торган эзләнүләр узган гасырның илленче елларында университет укытучысы Җәвад Алмаз тарафыннан җанландырып җибәрелә. Ул халык арасыннан җыеп алынган дистәдән артык кульязманы университет китапханәсенә тапшырып, аның фондларын баетуга үз өлешен кертә.

1960 еллардан диалектологик экспедицияләр эшчәнлегенә [20] бәйле үсеп киткән кульязмаларны туплау һәм фәнни әйләнешкә кертү эше даими археографик экспедициягә кадәр үсеп җитә. 1961 елның җәендә Диләрә Гариф кызы Тумашева Себергә, Бараба татарларына диалектологик экспедиция оештыра һәм Миркасыйм Габделәхәт улы Госмановны – ул вакытта татар теле һәм әдәбияты бүлегенең өченче курсында белем алган, Хатип Госманов һәм Шамил Мөхәммәдьяров җитәкчелегендә язма истәлекләрне өйрәнү белән шөгыльләнә башлаган студентны – үзе белән бергә Бараба якларына алып китә. Булачак галим, диалектологик эзләнүләр алып барудан бигрәк, Бараба татарларының фольклорын җыю һәм иске кульязма китапларны, гарәп язулы истәлекләрне эзләү белән мавыга. Шушы сәфәр вакытында ул Сәгъдинең «Бостан» әсәренә һәм Новосибирск өлкәсе Куйбышев районы Ум авылында «Бараба иле» дигән тарихи язмага тап була (Рәс. 1). Тубыл-Бараба тарихы чын мәгънәсендә кульязма мираска кызыксыну уята, кульязма «җене» кагылуга сәбәпче була.




*Рәс. 1. Тубыл-Бараба тарихы. Новосибирск өлкәсе, Куйбышев районы, Ум авылы. КДУ ДЭ-1961*

Бараба якларында алган тәэсирләрен М. Госманов Казанга кайткач, Ш. Мөхәммәдьяров белән уртаклаша, ә остазы, һич көтмәгәндә, археографик экспедиция оештырырга кирәк дигән фикерне җиткерә. 1963 елда Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсе Сергач районына һәм Оренбург төбәгенә Миркасыйм Госманов катнашында оештырылган өченче сәфәр аның җитәкчелегендәге беренче экспедиция була.

Шушы фатиха белән башланган археографик экспедиция ярты гасыр тирәсе дәвам итеп, татар дөньясына шактый исемнәрне, тарих тузанына күмелеп калган байтак ядкярләрне, басма китапларны кайтарып, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә. 1963–1989 еллар аралыгында әлеге экспедиция Казан университеты китапханәсендәге Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең Көнчыгыш кулъязмалары фондын 5831 берәмлеккә баету мөмкинлеген бирә: 1963 елга биредә 5701 берәмлек саналса, 1989 елга ул 11630 га кадәр арта. Әлеге гыйльми сәфәрләрнең өйрәнү географиясе Татарстан җирлегендәге торак пунктлардан тыш, Касыйм төбәгеннән алып, көнчыгышта Иркутск өлкәсенә кадәр, төньякта Пермь-Вяткадан башлап, көньякта Әстерханга кадәр территорияне үз эченә ала, «ягъни Россия Федерациясенең өчтән ике өлешендә эзләнүләр алып бара» [7, б. 153]. М. Госманов җитәкчелегендә оештырылган бу экспедицияләрдә ул вакытта университет галимнәре Х. Госман, М. Зәкиев, Ш. Мөхәммәдьяров, соңрак И. Гыйләҗев, Җ. Миңнуллин, Ф. Шәкүров, Р. Мәрданов, этнограф Р. Кашафетдинов һ.б. белән бергә системалы төстә студентлар да катнаша.

Кулъязмалар җыю, өйрәнү өлкәсендә күренекле археограф, Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш кулъязмалары секторы җитәкчесе Альберт Фәтхи эшчәнлеге аеруча хөрмәткә лаек. 32 елдан артык гомерен яраткан хезмәтенә багышлаган галим, җәй көннәрендә үзлегеннән гыйльми сәфәрләр оештыра, Татарстанның Кама арты, төньяк-көнчыгыш районнарында эзләнүләр алып бара. Кулъязмалар бүлегенең фондларын үстерү белән генә чикләнеп калмыйча, аларны өйрәнү һәм фәнни әйләнешкә кертүгә үзеннән зур өлеш кертә [16, б. 185–188].

Университет экспедициясе, матди сәбәпләр аркасында, 1990 еллар башында бөтенләй өзелү-тукталу чигенә җитә. Бары тик фидакарь җанлы галимнәребездән Җәүдәт Миңнуллин тырышлыгы белән генә бу гыйльми сәфәрләр тукталмый. Шул вакытта КДУ белән бергә Милли китапханәнең берләштерелгән археографик экспедициясен оештыру тәкъдиме туа һәм 1992 елның җәеннән ул рәсми төстә оештырыла башлый [2, б. 14]. Казан университетының Татарстан Милли китапханәсе белән берләштерелгән археографик экспедицияләре «1992–2009 һәм 2011-2012 елларда – барлыгы егерме ел дәвам итеп, бердәмлек белән, уртак максатларга бик нәтиҗәле хезмәт итә» [2, б. 16]. Күмәк экспедицияләрнең җитәкчесе университет ягыннан Җәүдәт Миңнуллин, Милли китапханәдән Рәиф Мәрданов (1992–2000), Ләззәт Хәйдәров (2001–2004), Ленар Гобәйдуллин (2006–2012) була. Әлеге сәфәрләрдә университетның татар филологиясе һәм тарихы факультеты (башта татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты), тарих факультеты студентлары белән бергә Чаллы педагогия институты студентлары да актив катнаша. Күмәк экспедиция шушы еллар аралыгында Оренбург, Пермь, Пенза, Ульяновск, Башкортстан, Чувашия, Түбән Новгород, Мари Иле, Удмуртия төбәкләрендә һәм

республикаларында, Татарстанның Әтнә һәм Биектау районнарында эшли. 1992 елдан 2012 елга кадәр егерме ел дәвамында барлыгы 3213 кульязма һәм басма китап табылып, киң фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелә. Алар арасында тарихи, әдәби һәм дини кульязма ядкярләр, гарәп язулы иске басма китаплар белән бергә «атаклы «Шура» һәм XX йөз башында нәшер ителгән башка бик күп татар журналларының төпләмәләре дә табыла» [7, б. 148]. 2012 елдан, кызганычка каршы, әлеге берләштерелгән экспедиция дә туктала.

Археографик экспедициянең нәтиҗәле эшләве Казан университеты фәнни китапханәсе Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш кульязмалар фондын ике тапкыр диярлек баетырга мөмкинлек бирә. Шушы вакыт аралыгында VII гасырдан алып, XX йөз уртасына кадәр вакыт эчендә иҗат ителгән сирәк китаплар, кульязмалар, ислам тарихына бәйле язмалар, астрономия, математика, география һәм фәннең башка тармакларына бәйле кулланмалар, авыл тарихлары, шәкерт дәфтәрләре, «Идегәй», «Түләк-Сусылу», «Кыйссаи Авык» дастаннары һ.б. фольклор үрнәкләре һәм матур әдәбият әсәрләре туплана. Алар арасында иң киң таралганы, әлбәттә, Коръән һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре була. Еш очрауларына карамастан, әлеге табышларның кыйммәтләре чиксез. Мәсәлән, 1982 елда Курган өлкәсенә оештырылган экспедиция вакытында Коръәннең XVI йөзгә караган бик борынгы күчермәсенә тап булалар (Рәс. 2). Китапханә фондында саклanучы әлеге кульязма Коръәннең иң борынгысы буларак та, Болгар территориясендә күчерелүе белән дә зур әһәмияткә ия [21, б. 93–105].



*Рәс. 2. Коръән. XVI йөз. Курган өлкәсе. АЭ-1982*

Болгар чоры әдәби ядкярләреннән булган «Кыйссаи Йосыф» әсәре татарлар арасында гаҗәеп күп таралган, көйгә салынып, яратып укылган әсәрләрдән санала (Рәс. 3).



*Рәс. 3. Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф»*

М. Госманов җитәкләгән экспедицияләр вакытында әсәрнең 77 күчермәсе табыла. Моннан тыш, археограф Альберт Фәтхи алып барган эзләнүләр «Кыйссаи Йосыф»ның 43 күчермәсенең китапханә фондларында тупланауына мөмкинлек тудыра. Бу күрсәткечләр әлеге әсәрнең таралыш һәм укылыш фактын дәлилли.

Әлбәттә, табылган барлык кульязма яки басма китаплар да феномен була алмый. Әмма аерым табышлар әдәбият тарихы өчен гаять зур ачышлар, яңалыклар алып килә, чыганаклар белән баета: урта гасыр төрки-татар әдәбиятына караган шактый әсәрләрне кайтару яисә дөнья күргән басмаларны баету, тулыландыру, әдәбият тарихына, әдип иҗатына яки шәхесенә карата яшәп килгән шаблон фикерләрне, мәгълүматларны үзгәртү, тулыландыру мөмкинлеген бирә. Мәсәлән, 1964 елда Түбән Новгород өлкәсе Сафаҗай авылына оештырылган экспедиция фәнни җәмәгатьчелеккә Хөсәен Фәезханов автографын «бүләк итә» (Рәс. 4). 1856 елда галим тарафыннан авылдашы Хәбибуллага язылган хат, әлбәттә, мөһим табышларның берсе була. Х. Фәезхановның башка автографлары 1986 елда Ш. Мәрҗанинең оныгы Д. Әмирханов тарафыннан тапшырыла [22, б. 12–18].



*Рәс. 4. Хөсәен Фәезханов автографлары. 1850-1860 еллар*

Тагын бер мисал: 1968 елда Буа районы Әхмәт авылына оештырылган экспедиция вакытында Мәхмүд Болгари тарафыннан язылган «Нәһҗ әл-фәрадис»ның 1855 елда күчерелгән кульязмасы табыла (Рәс. 5) һәм бу чор әдәбиятына бәйле аерым мәгълүматларны тулыландыру мөмкинлеген бирә.



*Рәс. 5. Мәхмүд Болгари. «Нәһҗ әл-фәрадис». Буа районы, Әхмәт авылы. 1968 ел.*

1969 елда Чүпрәле районы Иске Шәйморза авылында археографик экспедиция Г. Кандалый иҗат иткән «Мәгъшукнамә» әсәренең кульязмасына тап була (Рәс. 6). Бу табыш, бер яктан, әлеге әсәрне татар укучысына кайтаруы һәм фәнни әйләнешкә кертеп җибәрүе ягыннан кыйммәткә ия. Икенче яктан, әдипнең иҗаты турындагы әдәби фактларны баетырга мөмкинлек бирә. Моны дәлилләүче бер факт: Г. Кандалыйның 1960 елда басылган китабында 2500 дән артык шигъри текст дөнья күргән булса, М. Госманов тарафыннан төзелеп, 1988 елда чыккан басма 8500 юл текстны үз эченә ала [7, б. 154].



*Рәс. 6. Г. Кандалый. «Мәгъшукнамә». Чүпрәле районы, Иске Шәйморза авылы. АЭ - 1969*

1984 елда Мари Иле Бәрәңге районына оештырылган экспедиция вакытында Мазарбашы авылында Г. Утыз Имәни иҗат иткән «Горбәтнамә» әсәренең 1786 елгы кульязмасы табыла (Рәс. 7). Бу табыш китапханәдә саклanучы әлеге әсәрнең кульязмалары арасында иң борынгысы буларак бүген дә зур әһәмияткә ия.



*Рәс. 7. Г. Утыз Имәни. «Горбәтнамә», 1786 ел. Мари Иле, Бәрәңге районы, Мазарбашы авылы. АЭ-1984*

Моннан тыш, әдәби мирасыбыз үрнәкләреннән Мөхәммәдьяр, Габдерәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Габделҗаббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла кебек татар әдәбиятында тирән эз калдырган күренекле каләм ияләренең әлегә кадәр билгеле һәм билгеле булмаган әсәрләренең күчермәләре, аларның тәрҗемәи хәлләренә кагылышлы башка язма чыганаклар табыла. Шунысын да ассызыклап китү мөһим: күп кенә әдипләрнең әлеге экспедицияләр вакытында табылган әдәби мираслары соңыннан тикшерелеп, төп оригиналдагыча бастырып чыгарыла, галимнәр тарафыннан тикшерү объекты итеп алынып, әдәбият белеме үсешенә зур өлеш кертә.

Шул ук вакытта әлеге сәфәрләр вакытында башка төрки халыкларның әдәби ядкярләре дә табылып, татар халкының укымышлы, киң карашлы, дөнья әдәбиятыннан мәгълүматлы булуын тагын бер кат дәлилләргә, ассызыкларга мөмкинлек бирә. Татарларның көнчыгыш дөньясы, Урта Азия яклары белән тыгыз бәйләнештә яшәүләре – гомумбилгеле факт. Моннан тыш, татар мәдрәсәләрендә шәкертләр көнчыгыш дөньясында киң таралган китапларның күбесен дәреслек буларак файдаланганнар. Шуңа да татарлар яшәгән төбәкләрдә гарәп, фарсы, үзбәк, азәрбайҗан, казах, таҗик һ.б. телләрендә язылган әсәрләрнең күчермәләре еш очрый. Мисал өчен, 1968 елда Әстерхан өлкәсе Яңа авылда фарсы әдибе Ф. Гаттар иҗат иткән «Тәзкирәтел әүлия» әсәренең 1281 елгы күчермәсе табыла (Рәс. 8). Бу табыш – бүгенгә кадәр китапханә фондында саклanучы фарсы телендә язылган кульъязмаларның иң борынгысы.



*Рәс. 8. Гаттар. «Тәзкирәтел әүлия», 1281 ел. Әстерхан, Яңа авыл. АЭ-1968*

Тупланган кульъязмалар арасында төрекмән телендә язылганнары да бар. Мәсәлән, 1968 елда экспедиция әһелләре Әстерхан өлкәсендә Мәхтүм Колыйның шигъри әсәрләр җыентыгының XIX йөз ахырына нисбәтле күчермәсенә тап була (Рәс. 9). Әлеге табыш төрки халыклар арасында булган милли-мәдәни багланышлар тарихын өйрәнү өчен мөһим чыганак булып тора.



*Рәс. 9. Мәхтүм Колыйның шигъри әсәрләр җыентыгы. XIX йөз ахыры – XX йөз башы. Әстерхан өлкәсе. АЭ-1968*

Яисә үзбәк халкының төрки әдәбиятлар үсешенә зур йогынты ясаган билгеле шагыйре, олуг фикер иясе һәм дәүләт эшлеклесе Галишер Нәваи тарафыннан иҗат ителгән «Диван» әсәренең Буа районы Каенлык авылында табылган кульязмасы да кыйммәтле табышларның берсе [23, б. 73-75] була (Рәс. 10).



*Рәс. 10. Галишер Нәваи. «Диван», Буа районы, Каенлык авылы. АЭ-1968*

Шул рәвешле, әлеге экспедиция нәтиҗәсендә табылган кульязма һәм басма китаплар фәндә яшәп килгән күп кенә «ак тап»ларны бетерү, аерым фактларны төгәлләштерү юлында алыштыргысыз дәлил булып калка. Мондый сәфәрләр бу ядкярләрнең күбесен мәңгегә югалудан саклап калып, милли-мәдәни мирас төсендә киләчәк буыннарга тапшыру мөмкинлеген тудыра.

### Төп нәтиҗәләр

Ярты гасыр дәвам иткән экспедицияләр вакытында Россиянең 5 автономияле республикасы һәм 15 өлкәсендәге 900 гә якын торак пункт тикшерелә һәм төрки-татар, гарәп, фарсы телләрендә язылып, фәннең күп өлкәләрен колачлаган 10 000 нән артык кульязма, мең ярымга якын басма китаплар җыела һәм китапханә фондларына тапшырыла. Табылган кульязмаларның күпчелек өлешен дини эчтәлектәге Коръән Кәрим, Һәфтияк, төрле күләмдәге догалыклар, пәйгамбәрләр тарихына багышланган язмалар, дини васыятьнамәләр, салаватлар тәшкил итә. Моннан тыш, коллекциянең зур күләме тел, әдәбият, халык авыз иҗаты, тарих, медицина, әхлак өлкәләренә карый. Бу экспедицияләр кульязма ядкярләребезне җыю белән генә чикләнеп калмыйча, аларны өйрәнеп, күп текстларны беренчеләрдән булып фәнни әйләнешкә кертүгә ягыннан да бәһасез була.

Хәзерге көндә Казан университеты китапханәсендәге Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең Көнчыгыш кульязмалары секторында гарәп графикасында язылган 15000 нән артык кульязма саклана. Бу – Россия күләмендә иң зур күрсәткеч. Әлеге кульязмаларның 70 проценты – нәкъ менә археографик экспедициянең эшчәнлеге нәтиҗәсе! Алар бүген дә тарих, тел һәм әдәбият белеменә, гомумән, милләтебезгә хезмәт итә, хәзерге фәнни эзләнүләрнең дә өйрәнү объекты булып кала!

** Борынгы кульязма китапларның фотокопияләре Казан университеты Фәнни китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондыннан алынды.*

Тикшеренү эше ФПСП-2/24 темасы кысаларында башкарылды.

**Әдәбият**

1. *Госманов М.Г.* Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 463 б.

2. Милли китапханәнең археографик экспедицияләре: 30 еллык тәҗрибә / төз. Р. Мәрданов. Казан: «Милли китап» нәшр., 2022. 250 б.

3. *Усманов М.А.* Сколько потерь в каждой находке! // Памятники Отечества. Альманах Всероссийского общества охраны памятников истории и культуры. 1989. № 1. С. 115-124.

4. *Усманов М.А.* Итоги и перспективы археографических работ в Казанском университете // Материалы итоговой научной конференции КГУ за 1988 год: доклады на пленарных заседаниях. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. С. 3-20.

5. *Миңнуллин Җ.С.* Күренекле галим, әдип, җәмәгать эшлеклесе // Казан утлары. 2004. № 5. Б. 151-155.

6. *Миннуллин З.С.* Восточная археография в Казанском университете: страницы истории // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие

и перспективы изучения (К 80-летию профессора М.А. Усманова). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. С. 113-118.

7. *Миңнуллин Җ.С.* Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. 358 б.

8. *Крачковский И.Ю.* Собрание арабских рукописей в Казани. Избранные сочинения. М.-Л., 1960. Т. 6. 739 с.

9. *Әхмәтҗанов М.И.* Сайланма хезмәтләр. Казан: ТӘһСИ, 2019. 336 б.

10. *Усманова Д.М.* Миссия археографических экспедиций в сохранении и развитии традиций востоковедения и исламоведения в Казанском государственном университете // Ислам в мультикультурном мире: Мусульманские движения и механизмы воспроизводства идеологии ислама в современном информационном пространстве. Казань, 2014. С. 465-481.

11. *Усманова Д.М., Мустафина Д.А.* Традиции восточной археографии в Казани и Казанском университете // SLAVISTICA VILNENSIS. 2015. № 60. С. 203-223.

12. *Мустафина Д.А.* Вклад М.А. Усманова в основание и деятельность Археографической лаборатории Казанского университета // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы изучения (К 80-летию профессора М.А. Усманова). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2015. С. 61-69.

13. Татар факультетына 50 ел. Казан: Шәкли фәхем, 1994. 70 б.

14. Татар факультетына 60 ел. Казан: Казан ун-ты типографиясе, 2004. 143 б.

15. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты. Казан: Б. и., 2004. 42 б.

16. Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз. Раиф Мәрданов. Казан, 2007. 399 б.

17. Библиотека восточных историков, издаваемая И. Березиным. Т.II, Ч. I, Собрание летописей. Татарский текст с русским предисловием. Казань, 1854. XVIII, 128 с.

18. *Готвальд И.Ф.* Описание арабских рукописей, принадлежавших библиотеке Императорского Казанского университета. Казань, 1855. 302 с.

19. *Каримуллин А.Г.* Востоковедные фонды библиотеки Казанского университета им. В.И.Ульянова (Ленина) // Востоковедные фонды крупнейших библиотек Советского Союза. Статьи и сообщения. М., 1963. С. 228–236.

20. *Юсупов А.Ф., Файзуллина Г.Ч.* Школа татарской диалектологии в Казанском университете: предпосылки, формирование и развитие // TATARICA. 2024. № 22 (1). Б. 26-48.

21. *Гараева Н.Г.* Старейший список Корана в собрании Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета // Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения: Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.) / составители: Р.Ф. Исламов, С. Ф. Галимов. Казань, 2011. С. 93-105.

22. *Амерханова Э.И., Марданов Р.Ф., Сабирова Э.Н.* Сокровища мысли татарских просветителей // «Верность истине»: К 200-летию историка, лингвиста и педагога Хусаина Фаизханова: буклет выставки в Музее истории КФУ (18 мая – 3 июня 2023 года). Санкт-Петербург, 2023. С. 12-19.

23. Рукописи Алишера Навои в собраниях Казани. Каталог. / Составитель и автор описания рукописей – д. и. н. И.В. Зайцев. Москва – Казань – Тамбов, 2021. 192 с.

# АРХЕОГРАФИЧЕСКАЯ ЭКСПЕДИЦИЯ В КАЗАНСКОМ УНИВЕРСИТЕТЕ

**Айрат Фаикович Юсупов**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

**Энже Наилевна Сабирова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
Endzhe.Sabirova@kpfu.ru.

**Нурфия Марсовна Юсупова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

Археографическая экспедиция Казанского университета, посетив около 900 населенных пунктов в 15 областях 5 автономных республик России, вернула татарскому читателю более 10 000 рукописей на тюрко-татарском, арабском, персидском языках, около полутора тысяч печатных книг. Среди найденных рукописей преобладают книги религиозного содержания (Кораны, Хафтияки (часть Корана), молитвенники, истории пророков), ценные рукописи с произведениями народного творчества, трудами по языкознанию, по художественной литературе, истории, медицине. Эти экспедиции не только нацелены на сбор, накопление и научное исследование рукописных памятников, над которыми нависла опасность исчезновения, но прежде всего ориентированы на сохранение наследия культуры прошлого.

В статье содержится обзор редких рукописей, обнаруженных за полвека в ходе археографических экспедиций Казанского университета, выявлено научное и социальное значение этой работы в жизни татарского народа. В ходе исследования реконструирована история возникновения археографических экспедиций и содержание их работы, выявлен их вклад в развитие литературоведения.

**Ключевые слова:** Казанский университет, археографическая экспедиция, рукопись, печатная книга, научная работа

Исследование выполнено в рамках темы ФПСП-2/24.

Personalia

DOI: 10.26907/2311-2042-2024-23-2-135-141

# THE OUTSTANDING SOVIET AND RUSSIAN CARDIAC SURGEON

**Ravil Kalimullovich Akhmetshin,**
Plenipotentiary Representative of the Republic of Tatarstan in the Russian Federation,
Building 1, 13/15 3rd Kotelnichesky Per., Moscow, Russian Federation,
tat.msk@tatar.ru, dezh.pprt@tatar.ru.

**Airat Zakievich Farrakhov,**
State Duma of the Federal Assembly of the Russian Federation,
1 Okhotny Ryad Str., Moscow, Russian Federation,
ayrat.farrahov@minfin.ru.



**Akchurin Renat Suleimanovich** (1946–2024) was a surgeon, Doctor of Medical Sciences (1985), Professor (1992), Academician of the Russian Academy of Medical Sciences (RAMS), Russian Academy of

**Акчурин Ренат Сөләйман улы** (1946–2024) – хирург, медицина фәннәре докторы (1985), профессор (1992), Россия Медицина фәннәре академиясе академигы (1997), Россия Фәннәр академиясе академигы

**Акчурин Ренат Сулейманович** (1946–2024) – хирург, доктор медицинских наук (1985), профессор (1992), академик Российской академии медицинских наук (РАМН), Российской академии наук (2011),

Sciences (2011), Honorary Member of the Bashkir Academy of Sciences (1998) and Tatar Academy of Sciences (1999). R. Akchurin was the author and co-author of more than 900 scientific papers, including 8 monographs and 31 certificates of authorship. The scientist made a huge contribution to the preparation of highly qualified personnel: Under his supervision, 9 doctoral and 36 candidate dissertations were defended. R. Akchurin was awarded the Order of Honor (1996), of Friendship (2016), "For Services to the Fatherland" of IV degree (2021), the RKO medal for outstanding achievements in the development of Russian cardiology (2018), the Gold Medal named after N. Blokhin (2021) and the E. Chazov Gold Medal (2024). He was a Laureate of the USSR State Prize (1982) and the State Prize of the Government of the Russian Federation (2004).

(2011), Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы (1997), Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы (1999).

Р.С. Акчурин – 900 дән артык фәнни хезмәт авторы һәм автордашы, алар арасында 8 монография һәм 31 авторлык таныклыгы бар. Галим югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә зур өлеш кертте. Аның җитәкчелегендә 9 докторлык һәм 36 кандидатлык диссертациясе якланды. Р.С. Акчурин Почёт, (1996), Дуслык (2016), IV дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» (2021) орденнары, РКОның Ватан кардиологиясен үстерүдә зур казанышлары өчен, Н.Н. Блохин, Е.И.Чазов исемендәге алтын медальләр белән бүләкләнгән. СССР Дәүләт премиясе (1982), РФ Хөкүмәте (2004) премияләре лауреаты.

Почетный член Башкирской Академии наук (1998), Татарской Академии наук (1999).

Р. А. Акчурин – автор и соавтор более 900 научных работ, в том числе 8 монографий и 31 авторских свидетельств. Ученый внес огромный вклад в подготовку кадров высшей квалификации: под его руководством защищено 9 докторских и 36 кандидатских диссертаций.

Р. А. Акчурин был награжден орденами Почета (1996), Дружбы (2016), «За заслуги перед Отечеством» IV степени (2021), медалью РКО за выдающиеся достижения в развитии отечественной кардиологии (2018), золотой медалью им. Н. Н. Блохина (2021), Золотой медалью Е. И. Чазова (2024).

Является лауреатом Государственной премии СССР (1982), Государственной премии Правительства РФ (2004)

Renat Akchurin was born on April 2, 1946, to a family of teachers in the city of Andijan, the Uzbek SSR (now the Republic of Uzbekistan). After leaving high school in Andijan in 1964, he entered the Andijan Medical Institute; four years later he moved to the 1st Moscow Medical Institute named after I. Sechenov, from which he graduated in 1971.

The next year he spent working as a GP in the Reutov City Hospital, the Moscow Region, in 1972–1973 he held the position of trauma surgeon there. Concurrently, he worked as a part time surgeon at the 79th Hospital in Moscow and a trauma surgeon at the Balashikha District Hospital. In 1973, he was enrolled in the clinical internship in surgery at the All-Union Scientific Center of Surgery of the USSR Academy of Medical Sciences (VNCS USSR AMS). After completing his course in 1975, he was accepted as a junior research fellow in the Department of Microvascular Surgery at VNCS USSR AMS. In 1978, R. Akchurin defended his Ph.D. thesis "Organization and indications for microsurgical replantation of fingers and hands". In the same year, he became a senior research fellow in the Department of Vascular Microsurgery at VNCS USSR AMS. From 1984, he began to specialize in cardiac surgery. He completed an internship at the Michael DeBakey Clinic (Houston, USA). In the same year, he was elected to the position of head of the Department of Cardiovascular Surgery at the A. L. Myasnikov Institute of Clinical Cardiology of the Cardiology Research and Production Center, the Russian Academy of Medical Sciences.

"Starting from the first days of his work at the Cardiology Center, Academician Akchurin, for the first time in our country and Europe, introduced into clinical practice a highly effective microsurgical technology in operations on coronary arteries. This important and significant achievement made it possible to provide medical aid to patients previously considered inoperable, significantly reduce mortality and the number of complications during myocardial revascularization.

In addition to the introduction of microsurgical techniques in heart operations, Academician Akchurin introduced methods of using internal thoracic arteries for coronary bypass grafting, developed and improved specialized microsurgical instruments and suture material of domestic production for reconstructive microsurgery of the coronary arteries; he also developed methods of direct myocardial revascularization operations without artificial circulation, created an original myocardial stabilizer "Kosmeya" for this purpose, developed and improved complex surgical interventions in combined operations on the heart and blood vessels in patients with severe concomitant diseases (including cancer); introduced into practice and improved advanced surgical methods of treating cardiac rhythm and conduction disorders in various cardiovascular

diseases; due to his efforts new directions of cardiovascular surgery were developed and implemented in our country – endovascular and hybrid interventions for valvular heart disease and atherosclerotic lesions of the main vessels in the treatment of aneurysms of the aorta and its branches [1, c. 167].

Under the guidance of the prominent cardiac surgeon, the Department of Cardiovascular Surgery, developed and implemented his original concept of continuity of diagnostic, surgical and rehabilitation stages of treatment as an integral part of the high-tech surgery success.

R. Akchurin made a huge contribution to the organization and management of the federal target research and education program "High-tech Medicine". The famous cardiac surgeon was the deputy general director for surgery of the Federal State Budgetary Institution "Russian Cardiology Research and Production Complex" of the Ministry of Health of Russia.

For his achievements, the talented cardiac surgeon was thrice awarded the main prize at World Exhibitions in Belgium and Sweden. R. Akchurin's high medical expertise was confirmed by his membership of many academies and societies of the world. In 1994, the famous doctor became a member of the Scientific Council of the World Society of Angiologists, a member of the presidium of the Russian Society for Cardiovascular Surgery. R. Akchurin was a member of the board of directors of the DeBakey International Cardiovascular Surgical Society and a member of the European Society for CardioVascular Surgery [1].

We met more than twenty years ago. Our meetings became even more frequent when, under his leadership, the Doctors' Club was created at the Office of the Plenipotentiary Representative of Tatarstan in the Russian Federation in December 2011. This club has become a serious professional platform, enhancing close communication between doctors – the natives of Tatarstan and ethnic Tatars working in Moscow, its aim being to help our fellow countrymen. Among them are candidates and doctors of medicine, five academicians and physicians of the highest rank. Renat Akchurin himself was the chairman of the Council for the Defense of doctoral and candidate dissertations, so he could assess the value of scientific research - in 1985 he defended his doctoral dissertation "Reconstructive operations of the fingerless hand", and six years later he was awarded the academic title of professor in the specialty "cardiovascular surgery".

He was the creator of the world-renowned cardiac surgery school - 9 doctoral and 36 candidate dissertations were prepared and defended under his supervision. Renat Akchurin was the author of more than 900 scientific papers, including 29 monographs and chapters in monographs and had 31 certificates of authorship. He was also the editor-in-chief of the journal "Angiology and Vascular Surgery", a member of the editorial board of the "I. Grekov Surgery Bulletin", "Emergency Medical Care", "Circulation Pathology", "Cardiology Bulletin", "Cardiology and Cardiovascular Surgery", "Eurasian Cardiology Journal" and "Russian Electronic Journal of Radiology (REJR)" [2].

For many years, R. Akchurin headed the Department of Cardiovascular Surgery and Angiology, conducting a course in anesthesiology and resuscitation at the E. Chazov Institute for Training Highly Qualified Personnel of the Federal State Budgetary Institution the National Medical Research Center of Cardiology, the Ministry of Health of the Russian Federation. Today, outstanding and respected doctors work across Russia and in Tatarstan, they are his students and followers. He was very sensitive to their fate, taking care of each of them for many years.

Renat Akchurin maintained a close working relationship with Tatarstan for decades. At the medical instrument plant in the Republic of Tatarstan, they once developed and made a kit for coronary surgery, called the "Akchurin Kit". His cooperation with the enterprise and creation of these instruments became the reason for Renat Akchurin to pay his first visit to Kazan.

